**Сеҗе авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе**

2019 елның 07 июне Сеҗе авылы 14 сәг.00 мин.

Курса Почмак авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт, админ.бина
56 кеше катнашты.

Абзалова Л.У.: Хәерле көн, 2019 елның 26 мартындагы 1 нче номерлы Сеҗе авыл җирлеге башлыгы карары нигезендә бездә бүген Сеҗе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздырыла. Гавами тыңлаулар уздыру өчен җаваплы итеп, Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Гибадуллина Гөлфия Мансур кызы билгеләнде.

Секретаре: Мухамадиев Рөстәм Харис улы - авыл җирлекләренең хокукый мәсьәләләре буенча белгеч.

Сеҗе авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1,30-34 маддәсе, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә башланды.

Гавами тыңлаулар датасы турында мәгълүмат һәм кагыйдәләр проекты, карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, авыл җирлегенең торак пунктлары стендларында, түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган иде:

Сеҗе авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча халык тыңлаулары ТР, Арча районы, Курса Почмак авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт адресы буенча уздырыла. Гавами тыңлауларга кадәр Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегенең ҖҮЗ проекты буенча язма кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кермәде. Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлегенең ҖҮЗ проекты буенча язма һәм телдән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү сроклары 2019 елның 06 апреленнән 06 июненә кадәр. Шулай ук бернинди искәрмәләр һәм тәкъдимнәр килмәде.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклап калу өчен шартлар тудыру максатларында эшләнә, шәһәр төзелешен зоналаштыруга керәләр. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү яңа генераль планны раслау, РФ Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү белән аңлатыла.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре түбәндәгеләрне үз эченә ала: аларны куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибен; шәһәр төзелешен зоналаштыру картасын; шәһәр төзелеше регламентларын.

Гибадуллина Г.М.: Сораулар бармы? Гавами тыңлаулар барышында кисәтүләр булмады, кергән тәкъдим игътибарга алыначак. Әгәр сораулар юк икән, гавами тыңлаулар узды дип санала.

Гавами тыңлаулар уздыру өчен җаваплы Гибадуллина Г.М.
Секретарь Мухамадиев Р.Х.